Фатих Әмирхан, Һади Такташ, Гомәр Бәширов иҗаты буенча үткәрелгән викторина буенча отчет

2021 нче ел Туган телләр елы итеп билгеләнде. Туган тел һәркем өчен кадерле, газиз. Без үз туган телебездә сөйләшәбез, фикер алышабыз, хис-кичерешләребез белән уртаклашабыз. Туган телне саклау, яклау һәркемнең бурычы, шуңа күрә дә без туган телебезне үстерү, камильләштерү өстендә эшлибез.

22 гыйнвар көнне мәктәбебездә Фатих Әмирхан, Һади Такташ, Гомәр Бәширов иҗаты буенча викторина булып узды. Әлеге чара укучыларда туган телгә, матур әдәбиятка карата мәхәббәт тәрбияләү максатыннан үткәрелде. Викторина язучыларның юбилеена багышланды. Әлеге викторинада укучылар бик теләп катнаштылар. Монда укучылар язучыларның тормыш юлы, иҗаты буенча белгән белемнәрен күрсәттеләр.




